КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 7 декабрь г.Казань № 951

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә теркәлгән 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 11 март, 144 нче; 2016 ел, 24 март, 164 нче; 2016 ел, 15 август, 563 нче; 2017 ел, 21 февраль, 111 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм

күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә теркәлгән 1 нче кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлә).

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 7 декабрь, 951 нче карары редакциясендә)

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасында катнашучылар булып торучы адвокатлар хезмәте өчен түләү күләмнәре*

| Т/с | Түләүсез юридик ярдәм төре | Адвокатлар хезмәте өчен түләү күләме, сум |
|---|---|---|
| 1. | Хокукый консультация бирү: | |
| 1.1. | телдән | 400 |
| 1.2. | язмача | 700 |
| 2. | Түбәндәгеләрне язу: | |
| 2.1. | дәгъва гаризасы | 1000 |
| 2.3. | кассация (апелляция) һәм күзәтчелек шикаятьләрен | 1000 |
| 2.4. | соратулар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар | 500 |
| 3. | Дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарында, оешмаларда гражданнар мәнфәгатьләрен яклау ** | 1000 |
| 4. | Судларда гражданнар мәнфәгатьләрен яклау | 1500 |

*Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә адвокат хезмәте өчен түләү күләме адвокатка юридик ярдәм күрсәтү процессында түбәндәгеләргә транспортта барган очракларда кимендә 50 процентка арттырыла:

I төркем инвалид йортына;

стационар шартларда психиатрия ярдәмен күрсәтүче медицина оешмасына;

стационар шартларда өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмасына;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләренә, шулай ук балигъ булмаганнарны иректән мәхрүм итү урыннарына.

**Гражданнар мәнфәгатьләрен дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда, судларда яклау, адвокатның бер көн эчендә күпме вакыт эшләвенә бәйсез рәвештә, эшне үтәү белән фактта шөгыльләнгән көннәрдә исәпләнә.

---